**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы**
**Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты**
**КАРАРЫ**

2018елның 25 апреле 5№

2018 - 2020 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасын раслау турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы, 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 209-ФЗ номерлы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

2018 - 2020 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасын раслау турында(алга таба - Программа) расларга.

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

ТР Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: Ф.А.Акберов

Татарстан Республикасы Әлки
муниципаль районы Иске Камка авыл

җирлеге Башкарма комитетының
2018 елның 25 апрелендәге 5
номерлы карарына кушымта

2018 - 2020 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү
П Р О Г Р А М М АСЫ

Иске Камка авылы

**2018 - 2020 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасы ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Программа исеме | 2018 - 2020 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасы (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | 2014 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 209-ФЗ номерлы Федераль закон; 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | |
|---|---|
| | ; |
| Программа заказчысы | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаны чараларын башкаручылар | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаның төп максатлары | Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлегенең социаль-икътисадый бурычларын хәл итүдә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү һәм аларның ролен күтәрү өчен уңай шартлар тудыру; - кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының конкурентлыкка сәләтлелеген тәэмин итү; - Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына үзләре җитештерә торган товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) алга җибәрүдә ярдәм күрсәтү; - кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру; - халыкның мәшгульлеген тәэмин итү һәм үзмәшгульлекне үстерү; - талантлы яшьләрнең һәм потенциаль идарәчеләрнең кече һәм урта эшмәкәрлеккә керүен ачыклау һәм җәлеп итү;- барлык дәрәҗәдәге бюджетларның салым керемнәрендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан түләнгән салымнар күләме арту. |
| Программаны гамәлгә ашыру срогы | 2018-2020 еллар |
| Программаның төп чаралары исемлеге | - кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартларны камилләштерү; кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати, консультация һәм мөлкәт ярдәме күрсәтү; - кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә социаль яклау һәм хезмәтне саклау механизмнарын гамәлгә кертү. |
| Программаны тормышка ашырудан көтелгән нәтиҗә | - кече һәм уртаэшмәкәрлек субъектлары санын 20 %ка арттыру; - кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары хезмәткәрләренең уртача исемлек санын 2015 ел белән чагыштырганда 2019 елга 10 %ка арттыру; - кече һәм урта эшмәкәрлектә уртача хезмәт хакы күләмен тармакның уртача дәрәҗәсенә кадәр арттыру; - кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салым керемнәрен арттыру; - җирлек инфраструктурасын үстерү һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту; - үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр |

| | |
|---|---|
| | күләмен 2017 ел белән чагыштырганда 2019елга 20 %ка арттыру; |
| Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Татарстан Республикасы бюджеты, район бюджеты акчалары, бюджеттан тыш фондлар, эшмәкәрләрнең үз акчалары һәм җәлеп ителгән инвестицияләр |
| Программаның үтәлешен тикшереп тоту | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты |

**1.Гомуми нигезләмәләр**

Әлеге Программа 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнгән.

2003елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү мәсьәләләре керә.

2008 елның 1 гыйнварыннан «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары үсеше өчен шартлар тудыру кертелгән (алга таба текст буенча: ТКХ).

Әлеге Программаның максаты һәм төп бурычлары Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлтелгән.

Программа чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендәге максатларга ирешүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген, эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен билгели.

**2. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү**

Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлегенең икътисадый һәм социаль бурычларын хәл итүдә кече һәм урта эшмәкәрлек мөһим роль уйный, чөнки яңа эш урыннары булдыруга, кулланучылар базарын товарлар һәм хезмәтләр белән баетуга, конкурентлык мохитен формалаштыруга ярдәм итә, җирлек халкының икътисадый мөстәкыйльлеген, салым керемнәренең тотрыклылыгын тәэмин итә. Эшмәкәрлекне үстерү Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеген социаль-икътисадый үстерүнең өстенлекле бурычларыннан берсе булып тора.

Бүгенге көндә Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлегендә 3 шәхси эшмәкәр теркәлгән.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлегенең төп төре: кибетләрдә азык-төлек һәм сәнәгать товарларын ваклап сату.

Җирлекнең авыл хуҗалыгы предприятиеләре эшчәнлегенең төп юнәлеше - ашлык-ит-сөт җитештерү һәм шикәр чөгендере җитештерү. Соңгы вакытта дуңгызларның баш саны кими. Авыл хуҗалыгы оешмаларында баш санын киметүгә авыл хуҗалыгы предприятиеләренең авыр финанс хәле йогынты ясый. Авыл хуҗалыгы тармагында төп фондларның искерүе, сатыла торган продукциягә бәяләрнең түбән булуы һәм җитештерүнең үз хакын тәэмин итми торган субсидияләр түләүгә ставкаларның түбән булуы төп проблема булып кала.

СМСП үсешендә ярдәм итүче факторларны өч төркемгә бүлеп була:

1. оештыру проблемалары (предприятиене юридик рәсмиләштерү һәм теркәү белән кыенлыклар, үз эшеңне ачу һәм үстерү өчен кирәкле рөхсәт документларын алуда проблемалар (лицензияләр һ.б.), банкта счетлар ачу һ.б.);
2. матди-техник тәэмин итү (җитештерү һәм хезмәт бүлмәләре җитмәү яисә булмау, заманча җиһазлар, персоналның квалификациясе түбән булу, эшкуар эшчәнлегенең җитәрлек дәрәҗәдә якланмавы һ.б.);
3. матди-финанс проблемалар:

- предприятиене теркәү өчен капитал алуның кыенлыгы;
- әйләнеш чараларының җитмәве;
- эшчәнлекне киңәйтү өчен үз акчаларының да, заем финанс чараларының да җитмәве.

Күпчелек СМСП финанс хәленең тотрыксыз булуы һәм акчаларның җитмәве аркасында үз үсеше, яңа технологияләр кертү, продукциянең һәм хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү, озак сроклы инвестицияләрне гамәлгә ашыру, яңа базарларны үзләштерү өчен эчке стимуллардан мәхрүм. Эшмәкәрләрнең төп өлеше кредит һәм заем акчаларын кулланмый, барыннан да элек кирәкле тәэмин итү һәм кредит тарихлары булмау аркасында. Традиция буенча коммерция банклары кече һәм урта бизнесны хезмәт күрсәтүдә шактый күп көч таләп итә торган, югары куркыныч һәм чагыштырмача түбән керемле дип саныйлар. Югары кредит куркынычларын банклар эре бизнеска карата югарырак процент ставкалары исәбенә компенсацияләргә тырыша. Шуңа бәйле рәвештә кече һәм урта бизнесны кредитлау процессы әле массакүләм булмаган.

Эшмәкәрләрнең күбесе идарә һәм коммерция карарларын кабул итү өчен бизнес алып баруның төрле аспектлары турында мәгълүматка мохтаҗ. Кече һәм урта бизнесны мәгълүмати тәэмин итү проблемасы көндезге консультация тематик (махсуслаштырылган) басма кулланмалар белән хәл ителергә мөмкин.

Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты кече һәм урта бизнесны социаль тотрыклылыкның ышанычлы гаранты буларак карый һәм эшкә яраклы аз керемле һәм эшсез халыкны эш белән тәэмин итү бурычын хәл итә.

Җирлекнең реаль икътисадый потенциалы сарыф ителмәгән, кече һәм урта бизнеста хәл итәргә кирәк булган проблемалар да аз түгел.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының саны арту, кече һәм урта бизнес өлкәсендә халыкның мәшгульлеген арттыру, Әлки муниципаль районы икътисадының барлык тармакларында кече һәм урта бизнес предприятиеләре җитештергән продукция күләмнәрен үстерү җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциячел булмаган оешмалар гамәлләрен хуплау механизмнарын активлаштыру юлы белән генә ирешергә мөмкин. Шуңа бәйле рәвештә 2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасын кабул итү ихтыяҗы туа. Әлеге

Программаны кабул итү өчен хокукый нигез булып «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон тора.

Программа кече һәм урта эшмәкәрлекне алга таба үстерү өчен норматив-хокукый база булдыру, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс, мәгълүмати, консультация һәм мөлкәти ярдәм күрсәтү, шулай ук контроль процессын оештыру буенча комплекслы гамәлләр планыннан гыйбарәт.

## 3. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

3.1.Программаның төп максатлары:

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү һәм Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлегенең социаль-икътисадый бурычларын хәл итүдә аларның ролен күтәрү өчен уңай шартлар тудыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының конкурентлык сәләтен тәэмин итү;
- Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына үзләре җитештерә торган товарларны (эшләр, хезмәт күрсәтүләрне) алга җибәрүдә ярдәм күрсәтү;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру;
- халыкның мәшгульлеген тәэмин итү һәм үзмәшгульлекне үстерү;
- сәләтле яшьләрне һәм потенциаль идарәчеләрне ачыклау һәм кече эшмәкәрлеккә җәлеп итү;
- барлык дәрәҗәдәге бюджетларның салым керемнәрендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан түләнгән салымнар өлешен арттыру;

Куелган максатларга ирешүне Иске Камка авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының иҗтимагый берләшмәләр һәм эшкуарларның коммерциягә карамаган оешмалары, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары белән ведомствоара хезмәттәшлеге принципларында тормышка ашырырга тәкъдим ителә.

3.2. Куелган максатларга ирешү өчен хәл ителергә тиешле бурычлар: кече һәм урта эшмәкәрлекнең конкурентлыкка сәләтлелеген һәм инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру;

- җирлек икътисадының өстенлекле тармакларында кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм: инновацион эшчәнлек; хезмәт күрсәтүләр (көнкүреш, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә); азык-төлек (сөт, ит), милли һәм мәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алып һөнәрчелек; авыл хуҗалыгы (крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү);
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати ярдәм;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына консультация һәм оештыру ярдәме;

Программаның бурычлары аның соңгы максаты белән билгеләнә һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген активлаштыруга, яңа эш урыннары булдыруга һәм эшмәкәрлеккә җәлеп ителгән халыкның киң катламнарының тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итә торган уңайлы мохит булдырудан гыйбарәт.

## 4.Программаның төп принциплары

Программаның төп принциплары:

- ярдәм күрсәтүне сорап, - КУЭнең мөрәҗәгать итү тәртибе;

- КУЭ ярдәм итү инфраструктурасының һәркем файдалана алырлык булуы;

- Программада каралган критерийларга туры килә торган КУЭнең тиешле программаларда катнашуга тигез керүе;

- «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләрне үтәп, ярдәм күрсәтү;

- ярдәм күрсәтү процедураларының ачыклыгы.

## 5. Программаны гамәлгә ашыру срогы

Программаны гамәлгә ашыру срогы - 2018 - 2020 еллар.

## 6. Программа чаралары системасы

Программа чараларын гамәлгә ашыру бюджет акчаларыннан, бюджеттан тыш фондлардан финанслау шартларында гамәлгә ашырыла, 2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү программасы кысаларында җәлеп ителгән эшкуарларның үз акчалары.

Программаның чаралары Программада билгеләнгән бурычлар нигезендә эшләнгән.

### 2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасы исемлеге

| № | Чара атамасы | Нәтиҗә | Финанслау чыганагы | Финанслау күләме (мең сум). | | | | Башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | барлыгы | 2018 | 2019 | 2020 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ***1. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар камилләштерү*** | | | | | | | | | |
| 1.1 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү һәм аларга ярдәм итү мәсьәләләрен җайга сала торган муниципаль норматив-хокукый база булдыру | Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм | финансламыйча | - | - | - | - | | Каргалы авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| 1.2 | Әлки муниципаль районының кече һәм урта эшкуарлык вәкилләренең еллык конференциясендә катнашу | Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм | финансламыйча | - | - | - | - | | Каргалы авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| 1.3 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыра торган коммерциячел булмаган оешмалар, эшмәкәрләрнең иҗтимагый берләшмәләре белән аларның кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләре буенча фикерләрен исәпкә алу максатында үзара хезмәттәшлек | Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләүгә коммерциячел булмаган оешмаларны, эшкуарларның иҗтимагый берләшмәләрен җәлеп итү | финансламыйча | - | - | - | - | | Каргалы авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| 1.4 | Шәхси ярдәмче хуҗалыклар, крестьян-фермер хуҗалыклары һәм башка авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре җитештерә торган әзерләү продукциясе эшчәнлеген | Авыл хуҗалыгында кече һәм урта эшкуарлыкның тотрыклы үсешенә ярдәм | КУЭ чаралары | - | - | - | - | | Каргалы авыл җирлегенең башкарма комитеты |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | үстерү | | | | | | | |
| **2.Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына финанс ярдәме** | | | | | | | | |
| 2.1 | Аз санлы һәм ераграк торак пунктларга көндәлек ихтыяҗны товарлар белән тәэмин итүгә чыгымнар өлешен компенсацияләү | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм | бина өчен аренда түләвеннән азат итү | - | - | - | - | Каргалы авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| 2.2. | Милли һәм мәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алып, һөнәрчелек өлкәсендә КУЭ үсешенә ярдәм | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм | бина өчен аренда түләвеннән азат итү | - | - | - | - | Каргалы авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| 2.3. | Кече эшкуарлыкның яңа гына эшли башлаган субъектларына ярдәм | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм | бина өчен аренда түләвеннән азат итү | - | - | - | - | Каргалы авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| 2.4. | Яшьләр эшкуарлыгына ярдәм һәм аны үстерү | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына финанс-кредит акчалары алуда ярдәм | | - | - | - | - | Каргалы авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| **3. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мәгълүмати, консультация һәм мөлкәт ярдәме** | | | | | | | | |
| 3.1 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына оештыру ярдәмен гамәлгә ашыру һәм үстерү, шул исәптән: | | | - | - | - | - | Иске Камка авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| | «Елның иң яхшы | Эшкуарларның | финан | | | | | Каргалы авыл |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.1.1 | эшкуары» Әлки муниципаль районы эшкуарлары конкурсында катнашуны оештыру | казанышларын пропагандалау (популярлаштыру) | сламыйча | - | - | - | - | җирлегенең башкарма комитеты |
| 3.1.2 | Җирлекнең мәгълүмат стендларында мәгълүматны яктырту:<br>- юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны теркәү тәртибе;- эшкуарлык өлкәсендәге законнар;- эшкуарлык өлкәсендә ярдәм;- анонс;- файдалы мәгълүмат. | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын мәгълүмати тәэмин итү | финансламыйча | - | - | - | - | Каргалы авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| 3.1.3 | Мәгълүмат стендларында эшмәкәрлекне кредитлау шартларын яктырту | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын мәгълүмати тәэмин итү | финансламыйча | - | - | - | - | Каргалы авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| 3.2 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына консультация ярдәмен гамәлгә ашыру һәм үстерү | Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм | финансламыйча | - | - | - | - | Каргалы авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| 3.3. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм | финансламыйча | - | - | - | - | Каргалы авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| **4. Кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә социаль яклау һәм хезмәтне саклау механизмнарын эшләү һәм гамәлгә кертү** | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.1 | Хезмәтне саклау эшләрен оештыру мәсьәләләрендә консультация-методика ярдәме | КУЭ мәнфәгатьләрен яклау | финансламыйча | - | - | - | - | Каргалыавыл җирлегенең башкарма комитеты |

## 6. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслауның күләмнәре һәм чыганаклары Программа чаралары исемлеге белән билгеләнә.

## 7. Программа белән идарә итүне оештыру (программаны тормышка ашыру механизмы)

7.1 Программаны гамәлгә ашыру механизмы - билгеләнгән нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итүче җаваплы башкаручылар һәм сроклар буенча координацияләнгән программа чаралары системасы ул.

Программаның заказчысы - Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты, аның бурычына Программа чараларын үтәүне оештыру һәм башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген координацияләү керә.

Программа чараларын үтәү 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 209-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

7.2. Башкару п. 3.3. Программа чаралары исемлеге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 8. Программаны гамәлгә ашыруның барышын тикшереп тору

Программаны гамәлгә ашыруның барышын Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты тикшереп тора.

## 9. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашыру тулаем җирлектә икътисадый һәм социаль вәзгыятькә уңай йогынты ясаячак, инвестиция климатын яхшыртуга, җирлек инфраструктурасын үстерүгә, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының конкурентлыгын күтәрүгә һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртуга ярдәм итәчәк.

Программаны гамәлгә ашыру кысаларында, җирлектә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын арттырып, кече һәм урта бизнес секторында халыкны тотрыклы эш белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру күздә тотыла.

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге Программа чараларын финанслау һәм аларны үтәү дәрәҗәсенә бәйле.

- кече һәм уртаэшмәкәрлек субъектлары санын 20 %ка арттыру; - кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары хезмәткәрләренең уртача исемлек санын 2015 ел белән чагыштырганда 2019 елга 10 %ка арттыру; - кече һәм урта эшмәкәрлектә уртача хезмәт хакы күләмен тармакның уртача дәрәҗәсенә кадәр арттыру; - кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салым керемнәрен

арттыру; - җирлек инфраструктурасын үстерү һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту; - үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр күләмен 2017 ел белән чагыштырганда 2019елга 20 %ка арттыру;